СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
**23.04.2018**

Зеленодольск ш.

**КАРАР**
**№ 292**

«Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вазыйфа тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турында нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 12 июлендәге 206 номерлы район Советы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча аерым Указларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 11 декабрендәге ПУ-1092 номерлы Указын үтәү йөзеннән, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды**:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вазыйфаи тәртибе һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турында нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 12 июлендәге 206 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вазыйфаи тәртибе һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турында нигезләмәгә, түбәндәге эчтәлекле 3.2.6 пункт белән тулыландырып, үзгәрешләр кертергә:

«3.2.6. Мотивацияле бәяләмә үз эченә түбәндәгеләрне алырга тиеш:

а) әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгатьтә бәян ителгән мәгълүматны яисә әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының бишенче абзацында һәм «д» пунктчасында күрсәтелгән хәбәрнамәне;

б) рәсми мөрәҗәгатьләр нигезендә дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм кызыксынган оешмалардан алынган мәгълүматны;

в) әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгатьне алдан карау нәтиҗәләре буенча , яисә әлеге Нигезләмәнең «б» пунктчасының бишенче абзацында һәм 3.1 пунктының «д» пунктчасында күрсәтелгән хәбәрнамәләр, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 3.9, 3.10.3, 3.11.1 пунктлары нигезендә карарларның берсен кабул итү өчен нигезле нәтиҗә.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Зеленодольск**
**муниципаль районы**
**Башлыгы,**
**Советы рәисе** **А. В. Тыгин**